ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ                    БОЕРЫК

______________ с. Верхний Услон ______________

Коррупциягә каршы тору өлкәсендә Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру өчен җаваплы (җаваплыларны) билгеләү турында

«Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында

1. Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр кабул итү өчен җаваплы зат итеп Лазарева Татьяна Ивановнаны билгеләргә.

2. Т.И. Лазарева әлеге күрсәтмәнең 1 п. күрсәтелгән белешмәләрне кабул иткәндә, Татарстан Республикасы Президентына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы (dohod.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» җибәрелгән белешмә белән тәкъдим ителгән белешмәнең дөреслегенә тикшерү үткәрә дип билгеләргә.

3. Билгеләнгән тәртип нигезендә Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирә.

4. Советның оештыру бүлеге начальнигы Т.И. Лазарева отпускта булганда яисә хезмәттә булмаган башка очракларда Совет аппараты җитәкчесе Никитина Людмила Николаевнаны шушы боерыкның 1-3 пунктларында каралган бурычларын үтәү өчен вәкаләт бирергә.

5. Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру буенча вазыйфаи зат эшчәнлеген координацияләүне Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов

Таныштым: ____________________________

____________________________

____________________________